| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ РОДНИКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ РОДНИКИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

| | | |
|---|---|---|
| **РЕШЕНИЕ** | | **КАРАР** |
| 21.12.2023 | с. Родники | № 47 |

**Коррупциячел хокук бозулар кылган өчен Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Родники авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең җаваплылыгы турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

Муниципаль норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга, шул исәптән «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатларында

**Алексеевск муниципаль районы**
**Родники авыл җирлеге Советы карар итте:**

1.Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Родники авыл җирлеге Советының 2015 елның 21 апрелендәге 79 номерлы Карары белән расланган коррупциячел хокук бозулар кылган өчен Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Родники авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең җаваплылыгы турында Нигезләмәгә түбәндәге эчтәлектәге үзгәрешләр кертергә:

1) 2.4 пунктның 2 абзацын сүзләр белән тулыландырырга «, федераль законнар белән билгеләнгән очраклардан тыш.»;

2) 2.5 пунктның 2 нче абзацын сүзләр белән тулыландырырга «яки «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13.4 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенең вәкаләтле бүлекчәсе тарафыннан.».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтындагы «Родники авыл җирлеге»

бүлегендә, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

**Алексеевск муниципаль районы**
**Родники авыл җирлеге Башлыгы,**
**Совет рәисе** **Е.А. Яковлева**